КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 декабрь г.Казань № 1186

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче, 2019 ел, 19 ноябрь, 1049 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш

территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «Йомгаклау өчен» сүзләреннән соң «(үзгәреш)» сүзен өстәргә, «йомгаклауга (үзгәртү)» сүзләрен «үзгәртүгә (йомгаклау)» сүзләренә алмаштырырга, «(алга таба - гариза)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктның беренче абзацында «гаризага» сүзләренә кадәр «Килешү төзүгә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Килешүне үзгәртүгә гаризага түбәндәге документлар өстәлеп бирелә:

а) инвестиция проекты паспорты һәм инвестиция проектының төп күрсәткечләре әлеге Тәртипкә 2 нче һәм 3 нче кушымталар нигезендә форма буенча;

б) Бизнес-планның «10. Финанс-икътисадый нигезләү», «11. Кушымта» бүлекләрен, шулай ук бизнес-планның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 07 май, 284 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымтага ярашлы рәвештә форма буенча үзгәрешләр кертелә торган бүлекләре;

в) гамәлгә кую документларының һәм җитәкчене билгеләү турындагы карарларның (Килешү төзелүгә гариза бирелгән вакыттан алып гамәлгә кую документларына үзгәрешләр кертелгән һәм (яисә) җитәкче алмаштырылган очракта) күчермәләре;

г) гариза биргән көнгә кадәр 60 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта салым органы тарафыннан бирелгән салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү бурычын үтәве турында тиешле рәвештә таныкланган белешмә;

д) алдагы ике календарь ел өчен еллык һәм арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының күчермәләре һәм агымдагы елның узган хисап чорлары йә, әгәр шушы мизгелдән заявка бирү датасына кадәр кимендә ике календарь ел узса, юридик зат барлыкка килгән вакыттан алып узган барлык хисап чорлары өчен;

е) кредит оешмасыннан юридик затның агымдагы финанс хәле турында һәм «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы тору һәм террорчылыкны финанслау турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү турында мәгълүматны үз эченә алган белешмә.»;

4 пунктта «3 пунктның «г» - «з» пунктчаларында» сүзләреннән соң «яисә 31 пунктның «г» - «е» пунктчаларында» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта «гаризага» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта тиешле килешләрдә «гариза» сүзенә кадәр «Килешүне төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен, «3» санынннан соң «, $3^1$» саннарын өстәргә;

8 пунктта:

беренче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта:

беренче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

«а» пунктчасында «3» санынннан соң «, $3^1$» саннарын өстәргә;

«б» пунктчасында «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Килешү төзүгә (үзгәртүгә) гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә башкарма комитет бу хакта мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә хәбәр итә. Башкарма комитет Килешү төзүгә (үзгәртүгә) гаризаны кире кагу турында карарда гаризаны Килешү төзүгә (үзгәртүгә) гаризаны кире кагу турында күрсәтмә бирергә тиеш. Килешү төзүгә (үзгәртүгә) гаризаны кире кагу турындагы карарга законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.»;

11 пунктта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта:

беренче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «гаризада» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешүне төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен, «3» санынннан соң «, $3^1$» саннарын өстәргә;

җиденче абзацта «гаризада» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

13 пунктның беренче абзацында «гаризасын» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

15 пунктның беренче абзацында «гаризада» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә, «Гариза» сүзен «Килешүне төзүгә (үзгәртүгә) гариза» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

беренче абзацта «гаризаны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

17 пунктта:

беренче абзацта «гаризаны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

19 пунктта «гаризаны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә, «Гариза» сүзен «Килешүне төзүгә (үзгәртүгә) гариза» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктта «гаризаларны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

26 пунктта «гариза» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

27 пунктта:

беренче абзацта «гаризаны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

«а» пунктчасында «гаризада» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

28 пунктның беренче абзацында «гаризасы» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

31 пунктта «гаризаны» сүзенә кадәр «Килешү төзүгә (үзгәртүгә)» сүзләрен өстәргә;

$35^{1}$ пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) алгарышлы үсеш территориясе резидентының инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган икътисадый эшчәнлек төрләрен үзгәртү һәм тулыландыру, шулай ук алгарышлы үсеш территориясе резидентының инвестиция проекты атамасын үзгәртү;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин